Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«20» ноябрь 2020 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән Үрнәк авылы территориясендәге юлларны сезонлы карап тоту, юл кырыйларына таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком түшәү (сатып алу, ташу, җәю).
Үрнәк авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу.

Үрнәк авылы зиратын төзекләндерү һәм сезонлы карап тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үлән чабу).

Халык җыенында рәислек итүче: Р.А.Заһертдинова

Киекле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Заһертдинова